# КАРАР

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Войкино авыл җирлеге составына керүче Войкино авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

10 ноябрь 2019 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 11 ноябрендә «2020 елда Войкино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле мәсәләләрне хәл итүгә :

- җирлек эчендәге юлларны карап тоту;
- торак пунктлардагы урамнарны төзекләндерү һәм карап тоту;
- Войкино авылында чишмәне төзекләндерү;
- су белән тәэмин итү челтәрләрен карап тоту;
- торак пунктларда урамнарны яктыртуны карап тоту;
- балалар мәйданчыгы сатып алу;

ӘЙЕ ЮК

тоту белән килешәсезме? " мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 141 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 127 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде::

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 126 кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 1 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Войкино авыл җирлеге составына керүче Войкино авылындагы гражданнар җыены нәтиҗәләрен - вәкаләтле дип танырга.

2. “2020 елда Войкино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 Төркем инвалидларыннан, көндезге

бүлектә укучы блеге студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган

- җирлек эчендәге юлларны карап тоту;
- торак пунктлардагы урамнарны төзекләндерү һәм карап тоту;
- Войкино авылында чишмәне төзекләндерү;
- су белән тәэмин итү челтәрләрен карап тоту;
- торак пунктларда урамнарны яктыртуны карап тоту;
- балалар мәйданчыгы сатып алу;

ӘЙЕ ЮК

тоту белән килешәсезме? " мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Войкино авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Войкино авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Войкино авыл җирлеге башлыгы Н.П.Шабутдинова**